ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 15 апрелендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында» 2017 елның 23 июнендәге 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 50 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«**Татарстан Республикасында социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан, туристлык индустриясе объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында**»;

2) 1 статьяда «объектларыннан» сүзеннән соң «, туристлык эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә классификацияләнергә тиешле туристлык индустриясе объектларыннан («Кунак йортлары хезмәтләрен күрсәтү буенча эксперимент үткәрү турында» 2025 елның 7 июнендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә урнаштыру урыннарына караган объектлардан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән тыш) (алга таба – туристлык индустриясе объектлары)» сүзләрен өстәргә;

3) 2 статьяда:

а) исемендә «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә;

б) 1 өлештә «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә;

в) 2 өлештә «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә;

4) 4 статьяда:

а) исемендә «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә;

б) 1 өлештә:

1 пунктта «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә;

в) 2 өлештә:

1 пунктта «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә;

г) 3 өлештә:

беренче абзацта «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә;

3 пунктта «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә;

5) 5 статьяда:

а) исемендә «транспорт инфраструктуралары объектлары» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектлары» сүзләрен өстәргә;

б) беренче абзацта «транспорт инфраструктуралары объектларына» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларына» сүзләрен өстәргә;

в) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) туристлык индустриясе объектларына караган урнашу урыннары;»;

6) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 статья. **Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан, туристлык индустриясе объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеге өчен шартлар тудыруны тәэмин итү**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары (билгеләнгән вәкаләтләре өлкәсендә), оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмалар Федераль закон нигезендә социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан, туристлык индустриясе объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның (кресло-колясказарда йөрүче һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп) файдалану мөмкинлеге өчен шартлар тудыруны тәэмин итәләр.»;

7) 7 статьяда:

а) исемендә «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә;

б) 1 өлештә ике урында «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә;

в) 2 өлештә «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә;

г) 3 өлештә «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә;

8) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8 статья. **Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан, туристлык индустриясе объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү**

Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан, туристлык индустриясе объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү, шулай ук аларга бу очракта кирәкле ярдәм күрсәтү максатларында кабул ителгән Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары таләпләрен үтәү Федераль законның $15^1$ статьясы нигезләмәләре нигезендә тәэмин ителә.»;

9) 9 статьяда:

а) исемендә «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә;

б) 1 өлештә «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә;

в) 2 өлештә «транспорт инфраструктуралары объектларыннан» сүзләреннән соң «, туристлык индустриясе объектларыннан» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

2. Федераль законнар нигезендә «Татарстан Республикасында социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында» 2017 елның 23 июнендәге 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләре туристлык индустриясе объектларыннан инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә мондый объектларны төзү яисә реконструкцияләү өчен проект документациясен әзерләгәндә, шулай ук 2026 елның 1 сентябренә кадәр файдалануга тапшырылган мондый объектларга капиталь ремонт яисә реконструкция ясаганда 2026 елның 1 сентябреннән башлап кулланыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 25 апрель
№ 25-ТРЗ